КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 декабрь

г.Казань

№ 1659

2023 елда метрополитен вагоннарының күчмә составын (троллейбуслар) һәм тәгәрмәчле парларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен һлектр транспорты белән шәһәрдә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга субсидия бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023 елда метрополитен вагоннарының күчмә составын (троллейбуслар) һәм тәгәрмәчле парларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен һлектр транспорты белән шәһәрдә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга субсидия бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 21 декабрь, 1659 нчы
карары белән расланды

2023 елда метрополитен вагоннарының күчмә составын (троллейбуслар) һәм тәгәрмәчле парларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен цлектр транспорты белән шәһәрдә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга субсидия бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртиптә 2023 елда метрополитен вагоннарының күчмә составын (троллейбуслар) һәм тәгәрмәчле парларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен цлектр транспорты белән шәһәрдә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга субсидия бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү (алга таба шул ук эзлеклелектә – пассажирлар йөртү һәм багаж ташу, башка бюджетара трансфертлар) механизмы, максатлары һәм шартлары билгеләнә.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансфертлар 2023 елда әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертларны бирү шартлары:

пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы оешмаларга метрополитенның күчмә составын (троллейбуслар) һәм вагоннарның тәгәрмәчле парларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе билгеләнә торган муниципаль хокукый акт булу;

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен җитәрлек күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен кертеп) булу;

Министрлык һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча финанслашу максаты белән башка

бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге йөкләмәләре карала торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – 2023 елда пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда «даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты» күрсәткече ярдәмендә бәяләнә торган транспорт хезмәте күрсәтү ышанычлылыгы, аның күрсәткече троллейбуслар белән пассажирлар йөртү кимендә 0,7 һәм метрополитен белән пассажирлар йөртү кимендә 0,95 булырга тиеш.

2023 елга троллейбуслар белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты ($К_{распнтролл}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К_{распнтролл} = \frac{\sum Q_{фактрейс}}{\sum Q_{рейсрасп}} \geq 0,7,$$

монда:

$Q_{фактрейс}$ – троллейбуслар белән пассажирлар йөртүне һәм багажны ташуны гамәлгә ашырганда 2023 елда башкарылган факттагы рейслар саны;

$Q_{рейсрасп}$ – 2023 елга троллейбуслар белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда расписание белән билгеләнгән рейслар саны.

2023 елга метрополитен белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты ($К_{распметро}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К_{распметро} = \frac{\sum Q_{фактрейс}}{\sum Q_{рейсрасп}} \geq 0,95,$$

монда:

$Q_{фактрейс}$ – метрополитен белән пассажирлар йөртүне һәм багажны ташуны гамәлгә ашырганда 2023 елда башкарылган факттагы рейслар саны;

$Q_{рейсрасп}$ – 2023 елга метрополитен белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда расписание белән билгеләнгән рейслар саны.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗны финанс-икътисадый нигезләү теркәлгән, ирекле формада язылган башка бюджетара трансферт бирү турында заявка (алга таба – заявка);

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органы карарыннан, 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет исемлеге) турында өземтә, анда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет

исемлегендә) пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы оешмаларга метрополитенның күчмә составын (троллейбусларны) һәм вагоннарның тәгәрмәч парларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу раслана, бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларның күләме күрсәтелә;

пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы оешмаларга метрополитенның күчмә составын (троллейбуслар) һәм вагоннарның тәгәрмәчле парларын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе билгеләнә торган муниципаль хокукый акт күчермәс.;

7. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында яки башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәү;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

9. Министрлык тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә хәбәр ителә.

10. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органы әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

11. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкның башка бюджетара трансферт бирү турындагы карары кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелгән килешү нигезендә бирелә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны тапшыру формасы һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

Казан шәһәре муниципаль берәмлегендәге вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләре үтәлүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

13. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме (P) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P = (N_{тролл} \times K_{тролл} + N_{кп} \times K_{кп}) \times 50~\%,$$

монда:

$N_{тролл}$ – җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын да кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта, охшаш (бертөрле) товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турында мәгълүматны, шул исәптән җитештерүче оештыручыларның бәяләре турында мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт булган базар бәяләре (базарны анализлау) методы белән билгеләнә торган бер троллейбус кыйммәте, (әмма фактта башкарылган һәм документаль расланган чыгымнар), сум.

$K_{тролл}$ – 2023 елда 25 берәмлеккә тигез сатып алырга планлаштырыла торган троллейбуслар саны;

$N_{тролл}$ – җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын да кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта, охшаш (бертөрле) товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турында мәгълүматны, шул исәптән җитештерүче оештыручыларның бәяләре турында мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт булган базар бәяләре (базарны анализлау) методы белән билгеләнә торган метрополитен вагонының бер тәгәрмәч пары кыйммәте, (әмма фактта башкарылган һәм документаль расланган чыгымнар), сум.

$K_{кп}$ – 2023 елда 80 берәмлеккә тигез сатып алырга планлаштырыла торган метрополитен вагонының тәгәрмәч пары саны;

Шул ук вакытта Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган бюджет ассигнованиеләреннән һәм бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артык була алмый.

14. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең финанс органына ачылган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының бердәм счетына күчерелә.

15. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең вәкаләтле җирле үзидарә органы 2024 елның 1 гыйнварына кадәр Министрлыкка финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәсенә ирешү хакында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип рәвешенә кушып бирелә торган рәвешләр буенча хисап тапшыра.

16. Башка бюджетара трансфертлардан файдаланунын нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләрен 2023 ел йомгаклары буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләре белән чагыштырып карау юлы белән гамәлгә ашырыла.

17. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органы әлеге Тәртипнең 15 пункты нигезендә тапшырыла торган хисапларның дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

18. 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2024 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемենә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемենә түләтелергә тиеш.

19. 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органы тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, башка бюджетара трансфертлар Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына 2024 елның 1 апреленә кадәр тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

20. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары әлеге Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

21. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә вәкаләтле органы тарафыннан аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән әлеге Тәртипнең 18 һәм 19 пунктлары нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

22. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан башкарыла.